| | | |
|---|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ<br>РАЙОН», МЭР ГОРОДА<br>ЛЕНИНОГОРСКА | | «ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>ШӘҺӘРЕ МЭРЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.06.2021 г.Лениногорск №72

«Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2013 елның 15 мартындагы 41 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфаларны биләүче (муниципаль хезмәткәрләрне) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Президентының «Цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законның аерым нигезләмәләрен гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2020 елның 10 декабрендәге 778 номерлы Указы нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1. «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы, Лениногорск шәһәре мэрының 2013 елның 15 мартындагы 41 номерлы карары белән расланган Лениногорск муниципаль районы җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфаларны биләүче (муниципаль хезмәткәрләрне) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматларны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибенә түбәндәге үзгәреш кертергә:

2 пунктның «г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

г) җир кишәрлеген, күчемсез мөлкәтнең бүтән объектын, транспорт чарасын, кыйммәтле кәгазьләрне, акцияләрне (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлешен), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта алу буенча алыш-бирешләр кылган акчаларның гомуми суммасы муниципаль вазыйфаны биләүче затның һәм аның хатынының (иренең) соңгы өч елда гомуми кеременнән артып киткән очракта һәм алыш-биреш башкарылган средстволарны алу чыганаклары турында белешмәләр.»

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны рәсми публикатор - «Лениногорские вести» газетасында, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында http://leninogorsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасары С.В. Тимаковка йөкләргә.

Р.Г.Хөсәенов

Л.М. Галимова
5-18-52